**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 15 ноябре** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 26 ноябренә 08 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Балды-Кенә авылы, Гагарин урамы, 12 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.
2. 2022 елның 26 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Балды-Кенә авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Балды-Кенә авылы, Гагарин урамы, 12 йорты адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Балды Кенә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Балды Кенә авылының Гагарин урамында юлга вак таш җәю; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Балды-Кенә авылы зиратын коймалау һәм карап тоту; проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- светодиод лампалар сатып алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге (урамнар) буенча бүләргә.

5. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Нырья авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев